# Рус халык әкиятләре

# Шалкан



Бабай шалкан утырта.Шалкан зур үсә. Бабай шалканны тарта,тарта – тартып чыгара алмый.


Бабай әбине чакыра.



Әби килә. Әби бабайга,бабай шалканга тотына : тарталар, тарталар, тарталар- чыгара алмыйлар. Әби кызны чакыра.



Кыз килә. Кыз әбигә,әби бабайга, бабай шалканга :тарталар,тарталар – тартып чыгара алмыйлар. Кыз Акбайны чакыра.





Акбай килә. Акбай кызга, кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга: тарталар, тарталар – чыгара алмыйлар. Акбай Мыраубикәне чакыра.





Мыраубикә килә. Мыраубикә Акбайга, Акбай кызга,кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга : тарталар, тарталар – чыгара алмыйлар. Мыраубикә тычканны чакыра.






Тычкан килә. Тычкан Мыраубикәгә, Мыраубикә Акбайга,Акбай кызга,кыз әбигә,әби бабайга,бабай шалканга : тарталар,тарталар да тартып чыгаралар.







# Җавап бир:

1. Шалканны кем утырта?
2. Шалкан нинди булып үсә?
3. Бабай кемне чакыра?
4. Әби кемне чакыра?
5. Кыз кемне чакыра?
6. Акбай кемне чакыра?
7. Мыраубикә кемне чакыра?
8. Шалканны кем чыгара.
9. Син шалкан яратасыңмы?